
Бvген, кызганычка каршы, Мордовиянен топ елгаларынын берсе булган Мокша елгасы саега, vлән белән каплана – әйтерсен лә, сvнеп бара торган, «саега торган» һәм vлән белән капланган яр буе авылларынын язмышын кабатлый. Менә аларнын исемнәре: Акчеево, Ликинье, Лобановка, Вачеевка, Новое Кадышево, Мордовские Пошаты, Кабаново, Каменный Брод, Мельсяны, Старые Пичингуши һәм башка татар, мордва һәм рус авыллары. Бу безнен якын тирәдә генә. Ә Мордовия, Пенза, Тvбән Новгород, Рязань олкәләре буйлап ага торган елганын барлык ярларында алар кvпме!      Шунысы куанычлы: дәvләт Мокшаны савыктыру турында уйлый, монын очен федераль акчалар: 104 миллион сум бvлеп бирелгән. Росводресурслар хәбәр иткәнчә, «Экология» милли проекты буенча Мокша елгасын масштаблы чистарту эшләре башкарылган.
Кешелек доньясына ботен Жир планетасы турында житди уйларга вакыт инде. Планета климатынын Глобаль vзгәрешләренә багышланган халыкара конференцияләрдә мондый кисәтv янгырый: әгәр ашыгыч чаралар кvрелмәсә, доньяга монарчы кvрелмәгән янаулар, масштаблы корылык һәм су басулар, жимергеч циклоннар, тропик авырулар пандемияләре һәм халык миграциясе белән очрашырга туры киләчәк. Рәсми мәгълvматлар буенча, «планета халкынын яртысыннан артыгы инде бvген vк точе су житмәv һәм корылыкка дучар булган районнарда яши».
Мокша елгасы турында сойләгәндә, ботен планетабызга да шулай кагылдык. Донья бердәм. Ә Мокша, гел еракка омтылып, яр буендагы туган авылларын ташлап китми.